**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Зур Сукаеш авылы № 10 "18” апрель 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2015 елның 23 мартындагы 8 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе, Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2021 елның 14 декабрендәге 108-12 нче номерлы «Азнакай муниципаль районы җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Азнакай муниципаль районының авыл җирлекләренә тапшыру турында» карары нигезендә

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының башкарма комитетларына Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

торак мөнәсәбәтләре:

- Татарстан Республикасы муниципаль районының махсуслаштырылган торак фонды составыннан торак урыннарны кертү һәм төшереп калдыру;

- социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү;

- муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү;

- муниципаль торак фондында гражданнарга хезмәт урыны наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү;

- элек хосусыйлаштырылган торак урыннарын муниципаль милеккә кабул итү.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең түбәндәге башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне кабул итү турында килешү төзергә;

- Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатыннан бюджет законнары нигезендә 2022 һәм 2023-2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай

муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында проектын эшләргә һәм карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Җ.Закирова